**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » 10 2021 № 322

Аксубаево

2022 елга «Аксубай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының
норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларында норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 10 декабрендәге 326 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга кушымта итеп бирелә торган документны расларга:
«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2.Аксубай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган, белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль
районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең
18.10.2021 № 322
карары белән расланган

**«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җире | 97391 |
| | авыл җире | 98753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җире | 143889 |
| | авыл җире | 148363 |